ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

11.07.2019 | с. Верхний Услон | 639

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләләрен карау буенча эшче төркем төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, җир кишәрлекләрен рациональ һәм тиешле файдалануны тәэмин итү максатларында,Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан җир участокларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында «Кызыл Шәрык Агрохолдингы» АҖ генераль директоры В. Н Панков мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Кызыл Шәрык Агрохолдингы» АҖ милкендә булган һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән төрен үзгәртү зарурлыгы һәм максатка ярашлылыгы турындагы мәсьәләләрне карап чыгу һәм карау өчен эшче төркем төзергә.
2. «Кызыл Шәрык агрохолдингы» АҖ милкендә булган һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясенә караган җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән төрен үзгәртүнең кирәклеге һәм максатка ярашлылыгы турындагы мәсьәләләрне карап чыгу һәм карау өчен эшче төркем составын әлеге карарга №1 Кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе В.С. Тимиряев

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.07.2019 № 639 карарына
1 нче кушымта

«Кызыл Шәрык агрохолдингы» АҖ милкендә булган һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән төрен үзгәртү зарурлыгы һәм максатка ярашлылыгы турындагы мәсьәләләрне карап чыгу һәм карау өчен
СОСТАВ

| | |
|---|---|
| Тимиряев В.С. | Эшче төркем җитәкчесе: |
| | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Мингазов З.З. | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы; |
| Потапова Л.П. | МКУ «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» рәисе; |
| Салихов Е.М. | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| Губайдуллин Р.Г. | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| | «Кызыл Шәрык агрохолдингы» АҖ вәкиле (килешү буенча) |

.

Башкарма комитет эшләр идарәчесе А.К. Мингазова